Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урыны мәйданының исәпкә алу нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы турында» 2021 елның 20 апрелендәге 113 номерлы карары

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын һәм дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын билгеләргә, шуннан чыгып, гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында аларның торак урынының гомуми мәйданының гаиләнең бер әгъзасына гомуми мәйданы 18 кв. метрдан артмаган күләмдә торак урыны белән тәэмин итү дәрәҗәсе билгеләнә.

2.Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданын социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районында бер гражданга торак урынның гомуми мәйданының 18 кв. метр күләмендә бирү нормасын билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә торак урыны мәйданын бирү һәм исәпкә алу нормасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының 2020 елның 26 июнендәге 245 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Апас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А. А. Тугушев